Якты юл
Җомга, 19 июль 2019

# РӘКИТ ӘБДЕЛМАНОВ



*Рәкит Әбделманов (Рәкит АЛЛАБИРДЕ) Башкортостанның Кумертау районы Яңа Аллабирде авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында ала, Яңа Мораптал урта мәктәбен тәмамлый.*

*1978-1981 елларда хәрби диңгез флотында хезмәт итә. 1982 елда Татарстанга, Зәй шәһәренә, «КАМАЗ» оешмасына эшкә килә. Кичке сменада фажигагә эләгеп аягын югалта. 1983 елда Тәгәрмәчләр заводының оештыру бүлегендә эшли. 1984 елдан «Камгэсэнергострой» төзелеш берләшмәсендә өлкән мастер һәм 1985 елдан спорт биналары һәм корылмаларның баш инженеры вазифаларын башкара. 1986 елда Кама Автомеханика техникумының кичке бүлеген тәмамлый.*

*1996 елдан «Идел-Урал» хәйрия фондын оештыручы һәм җитәкчесе. Физик мөмкинлекләре чикләнгән актив кешеләрне туплаган фонд Рәсәй төбәкләренә һәм БДБ илләренә сәяхәтләр оештыра, спорт, мәдәни, хәйрия чаралары үткәрә. Рәкит Әбделманов – 2009 елда «Алтын йөрәкле кеше» һәм «Татарстан Республикасының ел хәйриячесе», 2010 елда Россия федерациясе «Благотворительность» сертификаты иясе, 2013 елда «Зур йөрәкле кеше» исемнәренә лаек була.*

*Шагыйрь-прозаик Рәкит Аллабирденең иҗатында ямьле-бай табигатькә эчкерсез-тырыш кешеләрнең бәйләнеше киң чагылдырыла. Иҗатында сөекле тормыш юлдашы Гөлчирәнең ярдәме зур. Сөю-мәхәббәт, гаиләгә катышлы әсәрләре күбрәк аңа багышлана.*

*Рәкит Аллабирденең шигырь һәм хикәяләре республика матбугатында даими басыла. Ул «Аллабирде» (1996), «Хыял атым» (2011), «Влюбленные души» (2012), «Җаным тама» (2016), «Сулыш» (2017), «Әтәч елы» (2017), «Яшьлегем тугае» (2018), «Алиһә» (2018), «Гашыйклар халәте» (2019) дип исемләнгән повесть, хикәяләр, шигырьләр җыентыклары авторы, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы.*

## БӘХЕТ

Гомер буе яктылыкка юллар салдым,
Тәкъдиремне җиңә-җиңә тау-таш ярдым.
Караңгыда нурлар күргәч, хәйран калып,
Бәхетемә дигән юлны таба алдым.

Бәхилләнеп бу дөньядан киткән чакта,
Минем эздән хозурланып калсын болын.
Шәригатьләп, матур итеп күмгән чакта,
Тәрбияләп, бер уч җирне салсын улым.

Сөйгән ярым гөл-чәчәкләр утыртканда,
Үз оныгым сулар ташып, сибеп торсын.
Сулкылдаган йөрәгендә бабам каны
Нәсел җебен тоташтырып тибеп торсын.

Кубарылып чыккан чакта минем җаным,
Исән булса сөйгән ярым, онык, балам,
Нурлар тулса түрләренә, тулса иман –
Мин сөенеп мәңгелеккә китә алам.

*06.02.2014 ел.*

## КАЙДА ТӨШИМ

Белсәм дә мин, баш имәгән – киселгәнне,
Гел сыгылып, билем бөгеп торалмадым.
Җилләр исеп куйган саен, яраклашып,
Җайлы гына тыныч тормыш коралмадым.

Белсәм дә мин, шуышканнар – егылмасын,
Һава ярып очкан мөлдә төшәлмәдем.
Кемнәрнеңдер күңеленә шифа булып,
Җиргә сеңеп, хәтфә булып түшәлмәдем.

*Һәр хуҗаны яклап-саклап, һау-һау өреп,*
Тәлинкәдән арткан сыйны кабалмадым.
Бил бөккәннәр, шуышканнар арасыннан
Максатыма иярченнәр табалмадым.

Таяк сугып, чиләк кагып куган саен,
Мин, өскәрәк күтәрелеп, җиргә багам:
Кайда гына сыенып соң, әйт син, гавәм,

*09.01.2014 ел*

## ХЫЯЛ АТЫМ

*Этләр өрә, кәрван бара...*
*Әйтем*

Яшәп булмый никтер салмак кына...
Хыял-атым һаман алдан йөри.
Тукталып бер каранмакчы булам –
Язмыш әллә мине алдап йөри...

Каерылып тартам авызлыгын,
Кубарылып чапкан атым тыеп.
Тыпырчына атым, пошкырына –
Хәвеф-хәтәр янда барын тоеп.

Аерырга телим кара-акны,
Салкын җилләр нигә каршы исә?
Караңгылык чорный тирә-якны,
Этләр өрү алда юлны кисә...

...Томырыла атым, авызлыгын өзеп,
Мәңгелектән артта калмас кебек.
Суырылып чыгам тоткынлыктан –
Күңелләрем инде талмас кебек.

Этләр өргән җирдә күкрәп яшәү
Язмышларда, бәлки, сирәктер дә...
Караңгыга дагаларны бәреп,
Очкын чәчеп үтү кирәктер дә!

*13.08.2008 ел*

## ОНЫК

Ата-ана дин юлында булгач –
Бу дөньялар яхшылыкка илтә.
Кыяр-кыймас тәүге адымнарын
«Иншалла» – дип бала башлап китә.

Изге юлдан атла матур итеп,
Шәригатькә биреп барлык көчең.
Мәгърифәткә әйдәп «Себер киткән»
Бабаларның изге рухы өчен.

Укымышлы булсын синең сүзләр.
Шәфкатьлеккә илтсен гыйлем эше.
Иң зур байлык безгә, бәрәкәтлек –
Син, кечкенә җанга газиз кеше.

*30.01.2016 ел*

## ӘТИ ИҢЕ

*Улым белән оныгыма*

Кошлар оча, елга өстен сыйпап...
Җил шаяра, дулкын белән уйнап.
Әти иңен «иярләгән» бала
Кама буйлап гүя атта чаба!

Яр буенда чыпчык оя кора...
И, шатланып бала карап тора.
Иң зур бәхет бүген аның өчен –
Әтисендә сизә яшәү көчен!

Кош баласы күктә канат каксын...
Газиз бала җирдә юлын тапсын.
Әти иңен тоеп үскән бала
Гомер буе хисле булып калсын!

Вакыт-вакыт сабый булып алсын!